**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

от 21.02.2014 №113-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2013 елның 19 ноябрендәге 670-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2013 елның 19 ноябрендәге 670-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

өченче бүлегендәге 3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультацияләр һәм ярдәм күрсәтү.

Мөрәҗәгать итүче, дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен, Министрлыкның җир ресурсларын саклау бүлегенә телефон, язмача һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Министрлыкның җир ресурсларын саклау бүлеге белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән, бирелә торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәте алу өчен башка мәсьәләләр буенча консультацияләр бирә һәм ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: составы, тапшырыла торган документлар формасы һәм бәяләмә алуның башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.».

2. Хокукый тәэмин итү бүлегенә (В.А.Тронин) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәү өчен җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары Р.И. Камаловны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр А.Г.Сидоров